РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
СОВЕТ КУКМОРСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
КУКМАРА МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ
СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

2019 елның 13 декабре

Кукмара шәһәре

№ 261

Кукмара муниципаль районы бюджетыннан Кукмара муниципаль районы шәһәр һәм авыл җирлекләре бюджетларына җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча җирле үзидарә органнары вәкаләтләрен үтәгәндә барлыкка килә торган чыгым йөкләмәләрен финанслашу максатларында субсидияләр бирү турында

Россия Федерациясе Бюджет кодексының 142.3 статьясы нигезендә Кукмара муниципаль районы Советы КАРАР БИРДЕ:

1. Кукмара муниципаль районы бюджетыннан Кукмара муниципаль районы шәһәр һәм авыл җирлекләре бюджетларына җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча җирле үзидарә органнары вәкаләтләрен үтәгәндә барлыкка килә торган чыгым йөкләмәләрен финанслашу максатларында субсидияләр бирү турында Тәртипне кушымта нигезендә расларга.

2. Әлеге карар нигезләмәләре Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы бюджетын төзегәндә һәм үтәгәндә, 2020 елга һәм 2021 һәм 2022 еллар план чорына бюджеттан башлап барлыкка килә торган хокук мөнәсәбәтләренә карата кулланыла.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Кукмара муниципаль районы Финанс-бюджет палатасы рәисе И.К. Сәмигуллинга йөкләргә.

4. Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникацион челтәрендә Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында http://kukmor.tatarstan.ru һәм Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында http://pravo.tatarstan.ru урнаштырырга.

Район Башлыгы С. Д. Димитриев

Кукмара муниципаль район Советының 2010 елның 13 декабрендәге 161 номерлы карарына кушымта

«Кукмара муниципаль районы» муниципаль берәмлеге бюджетыннан Кукмара муниципаль районы шәһәр һәм авыл җирлекләре бюджетларына җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча Кукмара муниципаль районы шәһәр һәм авыл җирлекләре җирле үзидарә органнары вәкаләтләрен үтәгәндә барлыкка килә торган чыгым йөкләмәләрен финанслашу максатларында субсидияләр бирү Тәртибе

1. Кукмара муниципаль районы бюджетыннан Кукмара муниципаль районы шәһәр һәм авыл җирлекләре бюджетларына субсидияләр җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча Кукмара муниципаль районы шәһәр һәм авыл җирлекләре җирле үзидарә органнары вәкаләтләрен үтәгәндә барлыкка килә торган чыгым йөкләмәләрен финанслашу максатларында бирелә (алга таба – субсидияләр).

2. Субсидияләр Кукмара муниципаль районы Советының «Чираттагы финанс елына һәм план чорына Кукмара муниципаль районы бюджеты турында» карарында каралган бюджет ассигнованиеләре һәм бюджет йөкләмәләре лимитлары чикләрендә 1 пунктта күрсәтелгән максатларда бирелә.

3. Кукмара муниципаль районының Финанс-бюджет палатасы әлеге карар нигезендә бирелә торган бюджет ассигнованиеләрен баш бүлүче булып тора.

4. Кукмара муниципаль районы шәһәр һәм авыл җирлекләре бюджетларына субсидияләрне бүлү Кукмара муниципаль районы Советының «Чираттагы финанс елына һәм план чорына Кукмара муниципаль районы бюджеты турында»гы карары белән раслана.

5. Субсидияләр бирүнең максатлары һәм тәртибе Кукмара муниципаль районы Башкарма комитеты һәм Кукмара муниципаль районы җирлеге Башкарма комитеты арасында төзелә торган килешүләр белән билгеләнә.

6. Килешүдә түбәндәге төп нигезләмәләр булырга тиеш:

а) субсидияләрнең максатчан билгеләнеше;

б) субсидия бирү һәм аны тоту шартлары;

в) субсидия бирүгә каралган бюджет ассигнованиеләре күләме;

г) субсидия күчерү графигы;

д) субсидия бирү һәм тоту өчен билгеләнгән шартларның үтәлешен тикшереп тору тәртибе;

е) финанс белән тәэмин итү чыганагы субсидия булган чыгымнарны гамәлгә ашыру турында хисап тапшыру сроклары һәм тәртибе.

7. Килешү проектын әзерләү Кукмара муниципаль районы Башкарма комитеты тарафыннан башкарыла.

8. Килешү проекты Кукмара муниципаль районы Башкарма комитеты тарафыннан Кукмара муниципаль районы авыл җирлеге башкарма комитетына

җибәрелә.

9. Килешү Кукмара муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе һәм Кукмара муниципаль районы җирлеге башкарма комитеты җитәкчесе тарафыннан имзалана.

10. Субсидия алу өчен Кукмара муниципаль районы җирлеге Башкарма комитеты Кукмара муниципаль районы Башкарма комитеты билгеләгән срокта Кукмара муниципаль районы Башкарма комитетына субсидия алу өчен Кукмара муниципаль районы Башкарма комитеты раслаган формада гариза һәм җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча шәһәр һәм авыл җирлекләренең җирле үзидарә органнары вәкаләтләрен үтәгәндә барлыкка килә торган чыгым йөкләмәләрен финанслашуга ихтыяҗны раслый торган башка документлар тапшыра.

11. Кукмара муниципаль районының Финанс-бюджет палатасы тарафыннан җирлекләр бюджетларына федераль казначылыкның Татарстан Республикасы буенча идарәсенең җирле бюджетлар үтәлешенә касса хезмәте күрсәтү өчен килешүдә билгеләнгән срокларда ачылган территориаль органнары хисапларына субсидияләр күчерелә.

12. Субсидияләр бирү шартларын бозган очракта, тиешле акчалар Россия Федерациясе бюджет законнарында билгеләнгән тәртиптә муниципаль район бюджеты кеременә күчерелергә тиеш.

13. Субсидияләр биргән елдан соң килүче елның 1 гыйнварына файдаланылмаган субсидияләр калдыгы Россия Федерациясе Бюджет кодексында билгеләнгән таләпләр нигезендә Кукмара муниципаль районы бюджеты керемена кире кайтарылырга тиеш.

14. Субсидияләрнең максатчан кулланылышын закон нигезендә Кукмара муниципаль районы Башкарма комитеты һәм Кукмара муниципаль районының Финанс-бюджет палатасы контрольдә тота.